Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино  авыл җирлеге составына керүче Юлсубино авылы    торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ  КАРАРЫ

2019  елның  30 октябре № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль  законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының  35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино  авыл җирлеге составына керүче Юлсубино авылы   торак пунктында гражданнар җыены  **КАРАР БИРӘ**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль  Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Юлсубино авылы   торак пунктында  тору урыны буенча  теркәлгән  сайлау хокукына ия булган  һәр кешесеннән, уку йортларына йөреп  ,көндезге бүлектә укучы студентлардан    гайре  300 сум күләмендә үзара салым  акчасы кертергә.
2. Тупланган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә:

- су белән тәэмин итү
- кышкы чорда Юлсубино   авылында  юлларны  карап   торуга:
- Юлсубино   авылында     Татарстан, Х.Такташ, Г.Тукай    урамнарын тоташтырган   юлны  төзекләндерүгә
- Юлсубино аылы мәдәният йортына  биллиард һәм башка кирәкле җиһазлар алуга
- Чишмәләр төзекләндерүгә
- Юлсубино авылы торак пунктында урам утлары куюга  һәм реконструкция ләүгә

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат  стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а  йорт; Ямаш авылы,Х.Такташ урамы, 3в йорт;     һәм Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы  үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен  җибәрергә.

Гражданнар  җыенында рәислек итүче,
Юлсубино  авыл җирлеге  башлыгы Х.Х.Гатиятов